ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.07.2022 г. Заинск № 356

**«2020-2022 елларга Зәй муниципаль районында урнашкан күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча төбәк программасын гамәлгә ашыруның кыска сроклы планың раслау турында» 2020 елның 06 апрелендәге 148 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм фонды турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль законны, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм фонды турында» 2007 елның 14 ноябрендәге ПУ-611 номерлы Указын, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән, «2020 - 2022 елларда Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1146 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны раслау турында» 2019 елның 27 декабрендәге 1220 номерлы карарына, Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «2020-2022 елларга Зәй муниципаль районында урнашкан күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планын раслау турында» 2020 елның 06 апрелендәге 148 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына (Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 30 ноябрендәге 541 номерлы карары белән

кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. 2020-2022 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча төбәк программасын гамәлгә ашыруның кыска сроклы планын расларга.»

1.2. 1 нче, 2, 3 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Зәй муниципаль районының http://zainsk.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе**
**вазыйфаларын башкаручы** **Р.М. Архипова**

Э.Н. Кулагина
(85558) 7-08-18

Юрист